**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1783**
**22.03.2024**

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, аларның кеременең һәм мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, 2024 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең максималь күләме – 49 835 сум 70 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 667 682 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 3 335 364 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 5 003 046 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 6 670 728 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 8 338 410 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 10 006 092 сум;

- җиде кешедән торган гаилә өчен – 11 673 774 сум;

- сигез кешедән торган гаилә өчен – 13 341 456 сум.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов